**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2016 ел, 24 октябрь № 774

г. Казань

Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгын Татарстан Республикасы Алабуга районы территориясендә төзелгән сәнәгать-җитештерү тибындагы махсус икътисадый зона белән идарә итү буенча вәкаләтләрне гамәлгә ашыруга вәкаләтле орган дип билгеләү турында

«Россия Федерациясендә махсус икътисадый зоналар турында» 2005 елның 22 июлендәге 116-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Икътисадый үсеш министрлыгының «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына Татарстан Республикасы Алабуга районы территориясендә төзелгән сәнәгать-җитештерү тибындагы махсус икътисадый зона белән идарә итү буенча аерым вәкаләтләр бирү турында» 2016 ел, 18 апрель, 241 нче боерыгы, 2016 ел, 5 сентябрь, С-577-АЦ/Д14 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына махсус икътисадый зона белән идарә итү буенча вәкаләтләр бирү турында килешү нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгын Татарстан Республикасы Алабуга районы территориясендә төзелгән сәнәгать-җитештерү тибындагы махсус икътисадый зона белән идарә итү буенча вәкаләтләрне, шул исәптән түбәндәгеләрне гамәлгә ашыруга вәкаләтле (проект документлары экспертизасын һәм инженер эзләнүләре нәтиҗәле экспертизасын үткәрүне тәэмин итү вәкаләтләреннән тыш) Татарстан Республикасы башкарма хакимият органы итеп билгеләргә:

махсус икътисадый зона резидентлары реестрын алып бару;

махсус икътисадый зона резидентлары таләбе буенча яки мәнфәгатьле затлар соратулары буенча махсус икътисадый зона резидентлары реестрыннан өземтәләр бирү;

Россия Федерациясе Икътисадый үсеш министрлыгының 2016 ел, 23 август, 530 нчы боерыгы белән расланган тәртиптә махсус икътисадый зона резидентының

сәнәгать-җитештерү, техник-гамәлгә кертү эшчәнлеген башкару турында килешүләрне үтәвен тикшерүдә тотуны гамәлгә ашыру;

Россия Федерациясендә махсус икътисадый зоналар турында» 2005 елның 22 июлендәге 116-ФЗ номерлы Федераль закон белән расланган тәртиптә техник-гамәлгә кертү яки сәнәгать-җитештерү эшчәнлеген гамәлгә ашыру буенча килешүләр төзү;

федераль бюджет, Россия Федерациясе субъекты бюджеты, җирле бюджет акчасы исәбеннән, әгәр бүтәне Россия Федерациясе законнарында билгеләнмәгән булса, махсус икътисадый зона чикләрендә территорияне планлаштыру һәм бу зонаның инженер, транспорт, социаль, инновацион һәм бүтән инфраструктураларын булдыру документларын әзерләү буенча дәүләт заказчысы функцияләрен үтәү.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков